**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**19 август 2019 ел** **№ 231**

**Нурлат шәһәренең Мактаулы гражданины турында Нигезләмәне раслау хакында**

Ватанны, кеше хокукларын һәм ирекләрен, гражданлык бурычын үтәгәндә кыюлык һәм батырлык күрсәткән районның җитештерү, мәгариф, мәдәният, муниципаль хезмәтен үстерүгә зур өлеш керткән гражданнарның күренекле уңышларын һәм казанышларын тану максатларында, Нурлат муниципаль районы Уставына таянып, Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Нурлат шәһәренең Мактаулы гражданины турында Нигезләмәне расларга (1нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мактаулы исемнәре һәм бүләкләре турында нигезләмәне раслау хакында» Нурлат муниципаль районы Советының 2006 ел, 28 гыйнвар 31/1 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына, ел саен Нурлат муниципаль районы бюджетын формалаштырганда, бүләкләр әзерләү һәм тапшыру, Нурлат муниципаль районы мактаулы бүләкләрен тапшыру белән бәйле чыгымнарны күздә тотарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль өлкә, мәдәният, мәгариф, тәрбия, спорт һәм яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы Советы рәисе А. С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль районы
Советының 2019 елның 19
августындагы 231 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Нурлат шәһәренең Мактаулы гражданины турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Нурлат шәһәренең мактаулы гражданины» (алга таба – мактаулы гражданин) исеме Нурлат шәһәре һәм аның халкы алдында аерым казанышларны иҗтимагый тануның иң югары формасы булып тора.

1.2. «Мактаулы гражданин» исеме гражданнарга түбәндәге шартларда бирелергә мөмкин:

- шәһәр һәм аның халкы хакына кылынган батырлык һәм геройлык (каһарманлык) өчен;

- икътисад, фән, мәдәният, сәнгать, спорт өлкәсендәге гомумтанылган казанышлар һәм район һәм шәһәр алдында башка мөһим казанышлар өчен;

- дөньядагы алдынгы казанышлар дәрәҗәсенә туры килгән һәм районның социаль-икътисади үсешенә ярдәм иткән күренекле ачышлар өчен;

- район халкы арасында нәтиҗәле мәдәни-агарту, иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге нәтиҗәсендә озак вакытка һәм тотрыклы танылу;

- «Мактаулы гражданин» исеме әлеге исемгә лаек булган гражданнарны Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән гражданлык бурычларын үтәү һәм вазыйфаларны башкару үрнәге буларак хезмәт итәргә мәҗбүр итә.

1.3. «Мактаулы гражданин» исеменә кандидатлар тәкъдим итү инициативасы белән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары (алга таба - район Советы), оешма, предприятие һәм учреждениеләр чыгыш ясый.

1.4. «Мактаулы гражданин» исемен бирү турындагы мәсьәләне карау Нурлат муниципаль районы башлыгы карары белән расланган бүләкләр буенча комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла. Тәкъдим ителгән материаллар нигезендә комиссия район Советына «Мактаулы гражданин» исемен бирү турында тәкъдим яки кандидатураны кире кагу турында дәлилләнгән җавап җибәрү турында карар кабул итә.

## 2. «Мактаулы гражданин» исемен бирү өчен документлар тапшыру тәртибе

2.1. Нурлат муниципаль районы башлыгы исеменә «Мактаулы гражданин» исемен бирү турындагы үтенечнамәләр юллана.

2.2. «Мактаулы гражданин» исемен бирү турындагы мәсьәләне карау комиссия тарафыннан Нурлат муниципаль районы башлыгы исеменә тапшырыла торган документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.3. Комиссия карары утырышта комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашу шарты белән, гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа комиссия рәисе һәм секретаре кул куя.

2.5 «Мактаулы гражданин» исемен бирү турындагы мәсьәләне карау өчен, Нурлат муниципаль районы башлыгы исеменә түбәндәге документлар тапшырыла:

- оешма җитәкчесе кул куеп, мөһер белән беркетелгән үтенечнамә;
- үтенеч бирүче коллектив җыелышы беркетмәсеннән өземтә;
- кандидатның казанышлары, булган дәүләт бүләкләре һәм казанышлары тасвирланган, «мактаулы гражданин»исемен бирү өчен әһәмияткә ия булган биография фактларын раслаучы документлар күчермәләре белән сыйфатламасы (кандидатның җентекле биографиясе).
- паспорт күчермәсе;
- бүләкләнүчеләрнең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы;
- 3 х 4 үлчәмле төсле, тонык 2 фотосурәт.

2.6. Бүләкләү турындагы документлар Нурлат муниципаль районы Советына Шәһәр көнен бәйрәм итүгә кадәр дүрт айдан да соңга калмыйча тапшырыла. Нурлат муниципаль районы башлыгы мактаулы гражданин исемен бирү өчен комиссия каравына кандидатура кертергә хокуклы.

## 3. «Мактаулы гражданин» исемен бирүгә документларны әзерләү, исәпкә алу һәм саклау тәртибе

3.1. «Мактаулы гражданин» исеме бирелгән гражданнарга тантаналы шартларда күкрәк билгесе, диплом, мактаулы исем бирү турындагы таныклык тапшырыла. Мактаулы исем таныклыгына Нурлат муниципаль районы башлыгы кул куя һәм Нурлат муниципаль районы Советының герблы мөһере сугыла. Нурлат муниципаль районы башлыгы мактаулы исем бирелү турындагы дипломга кул куя һәм Нурлат муниципаль районы Советының герблы мөһере белән раслый.

3.2. «Мактаулы гражданин» исеменә лаек булган гражданнар кабат әлеге бүләк белән бүләкләнә алмыйлар.

3.3. Батырлык кылган, кыюлык һәм каһарманлык күрсәткән өчен «Мактаулы гражданин» исемен бирү үлгәннән соң гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3.4. Күкрәк билгесен (исем һәм таныклык бирү турындагы карарны) югалткан очракта, бүләкләү турындагы карар дубликаты «Мактаулы гражданин»исеменә лаек булган гражданның гаризасы нигезендә бирелә.

3.5. Таныклык, дипломның дубликатлары бирелми.

3.6. Район Советы карары буенча, гамәлдәге законнар нигезендә мактаулы граждан, югары исемгә тап төшерүче эшләр һәм гамәлләр кылган очракта, исемнән мәхрүм ителергә мөмкин.

3.7. «Мактаулы гражданин» исеменнән мәхрүм ителгән очракта, таныклык һәм күкрәк билгесе район Советына кире кайтарылырга тиеш.

3.8. Мактаулы гражданнарның фамилияләре Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы төбәк музеенда саклана торган «Нурлат җиренең танылган кешеләре» китабына кертелә.

## 4. «Мактаулы гражданин» исемен тапшыру тәртибе

4.1. «Мактаулы гражданин» исемен бирү тантанасы елына бер тапкыр уздырыла һәм Шәһәр көнен бәйрәм итүгә туры китерелә.

4.2. Нурлат муниципаль районы башлыгы тарафыннан тантаналы шартларда күкрәк билгесен тапшыру башкарыла.

4.3. Күкрәккә тагыла торган билгене тапшыру шәхсән үзләренә, аңа лаек булган затларга башкарыла. Аерым очракларда, мактаулы исемгә лаек булган затларның шәхсән катнашуы мөмкин булмаган җитди сәбәпләр булганда, хөрмәтләү билгеләре, күкрәк билгеләре аларның вәкилләренә тапшырыла ала.

4.4. Күкрәк билгеләрен тапшыру тиешле беркетмәдә аларга лаек булган затлар яки аларның вәкилләре имзалары белән раслана. Саклау өчен беркетмәләр Нурлат муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә тапшырыла.

4.5. Шәхеснең, лаек булган затның үлеменнән соң күкрәк билгесе һәм таныклык, йөртү хокукыннан башка, варисларында истәлек итеп саклана. Күкрәк билгесе, таныклык һәм диплом, варислар ризалыгы белән, музейга тапшырылырга мөмкин.

## 5. Мактаулы гражданнар өчен ташламалар (өстенлекләр)

5.1. Мактаулы гражданнарның хокуклары:

- шәһәр транспортында бушлай йөрү (таксидан тыш);
- Нурлат муниципаль районы бюджеты хисабына бер тапкыр бирелә торган 10 000 сум күләмендә акчалата премия алу яки шушы бәягә белән туры килә торган кыйммәтле бүләккә ия булу.

5.2. Мактаулы гражданин яшәгән йорт фасадына аның ризалыгы белән мәгълүмати элмә такта куела.

5.3. Ташламалар (өстенлекләр) алу хокукы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының «Мактаулы гражданин» исемен бирү турында карары кабул ителгәннән бирле барлыкка килә.

5.4. Мактаулы гражданнарның әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән ташламалары, мактаулы граждан вафатыннан соң, аның гаилә әгъзаларына һәм башка туганнарына кагылмый.

5.5.Җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның әлеге Нигезләмәне тормышка ашыру белән бәйле чыгымнары район бюджеты акчасы хисабына каплана.